РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«24» март 2023 ел г. Альметьевск № 651

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елга Әлмәт муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 20 декабрендәге 3071 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

Төзәтүләр тәртибендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының «2023 елга Әлмәт муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның муниципаль программасын раслау турында» 2022 елның 20 декабрендәге 3071 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

1.1. Программа паспортының «Программа бурычлары» юлына түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

| | |
|---|---|
| Программа бурычлары | 6) Әлмәт муниципаль районында хокук тәртибен профилактикалау өлкәсендә хокук саклау органнары хезмәткәрләренең эш һәм потенциаль мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру өчен бүләкләү системасын булдыру; |

1.2. Программа паспортының «Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| Муниципаль программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет акчалыры исәбенә 4045,862 мең сум тәшкил итә.<br><br>Искәрмә:* Программаны муниципаль бюджет акчалары исәбеннән финанслау күләмнәре фаразлау характерында һәм, реаль мөмкинлекләрдән чыгып, төгәлләштерелергә тиеш. |

1.3. 2 бүлектә түбәндәге эчтәлекле 6 пункт өстәргә:

«6) Әлмәт муниципаль районында хокук тәртибен профилактикалау өлкәсендә хокук саклау органнары хезмәткәрләренең эш һәм потенциаль мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру өчен бүләкләү системасын булдыру.»;

23-120

Зак. № 305-2000

1.4. 3 бүлекнең беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны финанслауның гомуми күләме җирле бюджет акчалары исәбенә 4045,862 мең сум тәшкил итә.»;

1.5. 5 бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 9 пункт өстәргә:

«9) хокук бозуларны профилактикалауда яңа технологияләрне гамәлгә кертү һәм куллану өчен инновацион процессларны үстерү өчен шартлар тудыру.»;

1.6. 2023 елга Әлмәт муниципаль районында хокук бозуларны профилактикалауның муниципаль программасына түбәндәге эчтәлекле 6 бүлек өстәргә:

| 6 бурыч: Әлмәт муниципаль районында хокук тәртибен профилактикалау өлкәсендә хокук саклау органнары хезмәткәрләренең эш һәм потенциаль мөмкинлекләрен гамәлгә ашыру өчен бүләкләү системасын булдыру | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 6.1 Хокук саклау органнары хезмәткәрләре арасында конкурс үткәрү | ТР ӘМР БК | 2023 | | | | 275,862 |

1.7. «2023 ел өчен БАРЛЫГЫ: җирле бюджет акчалары:» юлларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| 2023 ел өчен БАРЛЫГЫ:<br>Җирле бюджет акчалары: | 4045,862 |

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район
Башкарма комитеты җитәкчесе А.М. Каюмов